**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**17.11.2021** г. Казань **№ 402**

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2018 елның 13 сентябрендәге 24 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында»гы 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында Типлаштырылган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»гы 2011 елның 8 ноябрендәге 1058 номерлы карары нигезендә **боерам**:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2018 елның 13 сентябрендәге 24 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 2019 елның 24 маенда 162 нче

номерлы, 2021 елның 11 мартында 57 нче номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

- «Министрлык эшчәнлегенә карата җәмәгать контролен гамәлгә ашыру.»;

2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Иҗтимагый советның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

яшьләр сәясәтен камилләштерүдә катнашу;

Министрлык тарафыннан карарлар кабул ителгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең мәгълүмат белән тәэмин ителүен арттыру;

җәмгыятьтә коррупцион гадәтләргә ризасызлык булдыру.»;

2 нче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 2.4 пункты белән тулыландырырга:

«2.4. Әлеге максатларга ирешү һәм куелган бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет:

яшьләр сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

коррупциягә каршы тору эшчәнлегендә катнаша;

«Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында»гы 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет утырышында алдан фикер алышудан башка кабул ителә алмый торган Министрлык тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрүне оештыра;

Министрлык тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты мониторингында катнаша;

Министрлыкның дәүләт сатып алуларының нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнаша;

дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләрен аттестацияләү өчен аттестация комиссияләре эшендә катнаша.»;

3.9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге Нигезләмәнең 6.6 пунктында каралган нигезләрнең булуы.»;

3.10 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү.»;

3.11 пунктында:

беренче абзацта «яисә рәис урынбасары» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «яисә рәис урынбасарына» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 6 нчы бүлек өстәргә:

«6. Иҗтимагый советта мәнфәгатьләр каршылыгы

6.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы - Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынуы аның үз вазыйфаларын тиешенчә, объектив һәм гадел үтәүгә (вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга) йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган һәм Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынуы белән Иҗтимагый совет әгъзасының максатлары, бурычлары арасында каршылык барлыкка китерергә мөмкин булган хәл.

6.2. Иҗтимагый совет әгъзасының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның объективлыгына һәм гаделлегенә йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынуы дигәндә, Иҗтимагый совет әгъзасы тарафыннан акча, төрле кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәт хокуклары, яисә үзе яки өченче затлар өчен хезмәт күрсәтү рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге күз алдында тотыла.

6.3. Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисе һәм министрга мәнфәгатьләр каршылыгы яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында белүгә үк хәбәр итәргә, ә Иҗтимагый совет рәисе Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына бу хакта язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

Иҗтимагый совет рәисе министр һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына мәнфәгатьләр каршылыгы яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында, бу хакта аңа билгеле булу белән язма рәвештә хәбәр итәргә бурычлы.

6.4. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында мәгълүм булган Иҗтимагый совет рәисе яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча, шул исәптән, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы билгеләгән тәртиптә башкарма орган җитәкчесенә мәнфәгатьләр конфликтын яклаучы иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктатып тору яисә туктату турында тәкъдим кертү юлы белән, чаралар күрергә тиеш.

6.5. Иҗтимагый совет рәисе яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы иҗтимагый Совет эшчәнлегендәге коррупциоген хәвеф-хәтәрләрне бәяли һәм Иҗтимагый совет әгъзаларының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашуына юл куймау максатларында аларны минимальләштерү буенча чаралар күрә.

Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүм булган Иҗтимагый совет рәисе өч эш көне дәвамында бу хакта министрга һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасына язма рәвештә хәбәр итә.

Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүм булган Иҗтимагый совет әгъзалары өч эш көне дәвамында бу хакта министрга һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасына язма рәвештә хәбәр итә.

6.6. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы министрга Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүмат алу очракларында иҗтимагый совет эшендә катнашуын туктатып тору турында тәкъдим кертә.

Министрның Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турындагы карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.

6.7. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә китерә торган шартлар юк ителмәсә яисә Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты расланса, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы министрга Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турында тәкъдим кертә.

Министрның Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турындагы карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.

6.8. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә китерә торган шартлар бетерелгән (расланмаган) һәм (яисә) Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты расланмаган очракта, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы министрга Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен яңарту турында тәкъдим кертә.

Министрның Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен яңарту турындагы карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Министр** **Т.Җ.Сөләйманов**